ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.01.2019 Казан ш. № 2

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының аерым боерыкларын үз көчләрен югалткан дип тану турында

"Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында" федераль законга һәм кунакханә хезмәтләре күрсәтүне һәм туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 5 февралендәге 16-ФЗ номерлы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре" 2014 елның 12 апрелендәге 234 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын һәм карарларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану хакында" 2018 елның 29 декабрендәге 1304 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыкларының көчен югалтуын танырга:

"Туристлык индустриясенең кунакханәләрне һәм урнаштыруның бүтән чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алган объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыручы оешмаларны аккредитацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 28 мартындагы 31 номерлы;

"Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына аккредитацияләнгән оешмалардан Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан кунакханәләрне һәм урнаштыруның бүтән чараларын, таудан чаңгы шуу трассаларын, комлыкларны үз эченә алучы туристлык индустриясе объектларына алар тарафыннан планлаштырылучы классификацияләүне гамәлгә ашыру турында белдерү тәртибен раслау турында" 2017 елның 27 мартындагы 33 номерлы.

Рәис С.Е. Иванов